**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

---

2018 елның 1 феврале 49№

**ПОСТАНОВЛЕНИ** **КАРАР**

«Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты
каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча
иҗтимагый координация советы»н төзү турында

Татарстан Республикасында 2017 елның 24 октябрендәге ПР-313 номерлы террорчылыкка каршы комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә һәм Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү, аларның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеге, Әлки муниципаль районында яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында карар бирәм:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координация Советын (алга таба - Яшьләр координация Советы) төзергә.
2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координация Советы турындагы нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Яшьләр координация Советы составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Яшьләр координация Советы эшчәнлеген тәэмин итүне Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.А. Платоновага йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В.Юсупов

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 1 февралендәге 49 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координация Советы турындагы НИГЕЗЛӘМӘ**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлки муниципаль районы яшьләре белән эшләү буенча иҗтимагый координация советы (алга таба - Яшьләр координация Советы) Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү, аларның дәүләт хакимияте органнары, яшьләр структуралары белән хезмәттәшлеге, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр сәясәте көчләрен берләштерү һәм бердәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча яшьләр сәясәте субъектларының килешенгән гамәлләрен эшләү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында Әлки муниципаль районы яшьләренең иҗтимагый консультатив-киңәшмә органы булып тора.

2. Яшьләр координация Советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе законнары, шул исәптән "Иҗтимагый берләшмәләр турында" һәм "Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме турында" федераль законнар, "Яшьләр сәясәте турында" Татарстан Республикасы Законы, Әлки муниципаль районы Уставы, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр координация Советы эшчәнлеге законлылык, коллегиальлек, хәбәрдарлык һәм барлык әгъзаларының тигез хокуклы булуы принципларына нигезләнә.

**2. Яшьләр координация Советы максат һәм бурычлары**

Яшьләр координация Советы максатлары:

- Әлки муниципаль районында яшьләр белән эшләүнең өстенлекле юнәлешләре торышын анализлау һәм аларны билгеләү;

- яшь гражданнарны Әлки муниципаль районының иҗтимагый-сәяси тормышында турыдан-туры катнашуга җәлеп итү;

- яшьләр проблемаларын хәл итүгә, яшьләр социаль инициативаларын алга җибәрүгә, шулай ук Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программасына кагылышлы республика һәм район максатчан программаларын гамәлгә ашыруда яшьләрнең катнашуы өчен шартлар тудыру;

- социаль, мәдәни, рухи һәм физик үсешкә, яшьләрне патриотик тәрбияләүгә һәм аларга белем бирүгә ярдәм итү, яшьләрдә толерантлык, милләтара һәм диннәр арасындагы ихтирам идеяләрен тәрбияләү.

2.2. Яшьләр координация Советы эшчәнлегенең төп бурычлары:

- Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, консультатив-киңәшмә органнарының һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, яшьләрнең рухи һәм физик үсешенә, патриотик тәрбиягә, яшьләр арасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга, дәүләт яшьләр сәясәте, мәгариф, мәдәният,

спорт һәм ял итү өлкәсендә муниципаль яшьләр чараларын гамәлгә ашыруда милек рәвешләренә бәйсез рәвештә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә, муниципаль районның мәгариф учреждениеләренә, башка оешмаларга социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

- яшьләрнең актуаль проблемаларын хәл итүдә дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, муниципаль районның мәгариф учреждениеләренең, яшьләр клубларының һәм башка оешмаларның эшчәнлеген координацияләү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- яшьләр белән эшләүдә ведомствоара нәтиҗәле хезмәттәшлекне, социаль партнерлыкны тәэмин итү;

- Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда барлык кызыксынган оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең көчләрен һәм мөмкинлекләрен берләштерү;

- балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең хокук бозуларын социаль ярдәм һәм реабилитацияләү проблемаларын комплекслы хәл итүне тәэмин итү, халыкны эш белән тәэмин итү һәм җәмәгать ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыру;

- муниципаль район яшьләрен теләкләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру,

- яшьләрнең иҗади һәм гражданлык активлыгына ярдәм итү;

- яшьләр турында уңай җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша;

- яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актларны карауга әзерләү буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы комиссияләре эшчәнлегендә катнашу;

- Әлки муниципаль районы Советында яшьләр мәнфәгатьләрен яклау;

- яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы җирле һәм региональ хокукый актлар әзерләүдә катнашу;

- Әлки муниципаль районы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны иҗтимагый тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

- Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче яшь кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

- яшьләр арасында яшьләрнең хокукый мәдәниятын күтәрүгә, милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә, яшьләрдә террорчылык һәм экстремизм идеологиясен тотрыклы кабул итмәүгә юнәлдерелгән актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлтелгән агарту һәм аңлату эшләре алып бару;

- яшьләрнең хокукый һәм сәяси мәдәниятын күтәрү максатында мониторинглар һәм социологик тикшеренүләр, консультацияләр, конференцияләр һәм очрашулар семинарлары уздыру;

- җирле үзидарә органнарына кадрлар резервын әзерләү өчен оештыру сәләтләренә, лидерлык сыйфатларына ия булган яшь кешеләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

2.3. Яшьләр координация Советы хокуклы:

- кирәк булганда үз эшенә куелган бурычларны нәтиҗәле хәл итү өчен консультантларны, экспертларны һәм аның составына кермәгән оешмалар белгечләрен җәлеп итәргә;

- Яшьләр координация Советы компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча аерым мәсьәләләр һәм эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча, материаллар һәм норматив хокукый актлар проектларын әзерләү һәм эшләү өчен эшче төркемнәр төзергә;

- Яшьләр координация Советы әгъзалары, килештереп, дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча эш тәҗрибәсен өйрәнү максатында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына чыгуларда катнашырга мөмкин.

**3. Яшьләр координация советы функцияләре**

1. Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру процессында барлык кызыксынган затларның һәм яшьләр сәясәте субъектлары структураларының гамәлләрен координацияләү.

2. Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча килешенгән карарлар һәм гамәлләр кабул итү.

**4. Яшьләр координация Советының составы һәм аны төзү тәртибе**

4.1. Россия Федерациясенең Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче, түбәндәге категорияләргә керүче теләсә кайсы гражданнары Яшьләр координация Советы әгъзалары булырга мөмкин:

- Татарстан Республикасының район яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре;
- муниципаль районның гомуми белем бирү учреждениеләреннән яшьләр вәкилләре,
- Татарстан Республикасында гомумроссия яшьләр иҗтимагый оешмалары бүлекләре вәкилләре;
- Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында, муниципаль районның вәкиллекле органы депутатлары тарафыннан тапшырылган сәяси партияләр вәкилләре;
- яшьләр сәясәтенең бурычларын бергәләп хәл итү белән кызыксынган эшләүче яшьләр арасыннан активистлар.

4.2. Яшьләр координация Советы әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

4.3. Яшьләр координация Советы эшчәнлеген Совет рәисе, ә ул булмаганда - Яшьләр координация Советы урынбасары җитәкли.

4.4. Яшьләр координация Советы рәисе муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдиме буенча Яшьләр координация Советы әгъзалары арасыннан раслана.

4.5. Яшьләр координация Советы составы муниципаль район Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.6. Яшьләр координация Советы әгъзалары була алмый:

- суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;
- төшерелмәгән яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;
- икеләтә гражданлыгы булган затлар.

4.7. Яшьләр координация Советында әгъзалыкны туктату өчен нигезләр:

- Яшьләр координация Советы әгъзасының составыннан ирекле чыгу турында шәхси язма гаризасы;
- Яшьләр координация Советы әгъзасының утырышларда һәм Совет эшендә даими катнашмавы;
- әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында бәян ителгән таләпләрне үтәүне мөмкин булмаган хәлләрне ачыклау;
- Яшьләр координация Советы әгъзасының үлеме.

**5. Яшьләр координация Советының эш тәртибе**

5.1. Яшьләр координацион Советы эшен Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары алып бара, муниципаль район башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт, мәгариф, мәдәният бүлекләре координацияли.

Совет Татарстан Республикасы Яшьләр форумы карарлары, муниципаль районның яшьләр активының гомуми җыелышы нигезендә төзелгән план, шулай ук Яшьләр координация Советы әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә эшли.

5.2. Яшьләр координация Советы утырышы кирәк булган саен, елга 2 тапкырдан ким булмаган санда үткәрелә.

5.3. Яшьләр координация Советы үз эшен еллык эш планы нигезендә төзи.

5.4. Эш планы Яшьләр координация Советы әгъзаларының тәкъдимнәрен коллегиаль юл белән формалаштырыла һәм Советның чираттагы эш утырышында раслануга чыгарыла.

5.5. Яшьләр координация Советының эш планы җаваплы сәркатип тарафыннан төзелә, Совет утырышында карала һәм раслана.

5.6. Яшьләр координацион Советы сәркатибы Совет әгъзаларына Совет утырышын үткәрүнең датасы, урыны, вакыты, көн тәртибе проекты турында Совет уздыруга кимендә 14 көн кала хәбәр итә.

5.7. Совет әгъзаларының исемлек составының 2/3 нән дә ким булмаган өлеше булса, Совет утырышы үткән санала.

5.8. Совет утырышлары ачык булып тора.

5.9. Совет утырышы йомгаклары буенча рәис һәм җаваплы сәркатип тарафыннан имзаланган утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә.

5.10. Яшьләр координация Советы карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә, беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, алар Совет рәисе яисә аның утырышта рәислек итүче урынбасары тарафыннан имзалана.

5.11. Яшьләр координация Советының яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча карарлары Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына җибәрелә.

5.12. Яшьләр координация Советының үз компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары киңәш характерында.

**6. Яшьләр координация Советы рәисенең вәкаләтләре**

6.1. Яшьләр координация Советы эшчәнлеге белән җитәкчелек итә.

6.2. Яшьләр координация Советы рәисе Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдиме буенча Яшьләр координация советы әгъзалары арасыннан раслана.

6.3. Яшьләр координация Советы рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Яшьләр координация Советы эшчәнлеген перспективалы һәм агымдагы планлаштыруны оештыра, аның эш планнарының үтәлешен тикшереп тора;

2) Яшьләр координация Советының утырышларын һәм аны карауга кертелә торган мәсьәләләрне әзерләүгә җитәкчелек итә, Яшьләр координация Советы утырышының көн тәртибе проектын раслый;

3) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, сәяси партияләрнең региональ һәм җирле бүлекчәләре, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук башка затлар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләрдә Яшьләр координация Советын тәкъдим итә;

4) Яшьләр координация Советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә;

5) Яшьләр координация Советы Рәисе урынбасарына, сәркатибына һәм әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

6) Яшьләр координация Советы карарларын гамәлгә ашыруны тикшереп тора;

7) Яшьләр координация Советының карарларын, беркетмәләрен, тәкъдимнәрен, мөрәҗәгатьләрен, хатларын һәм мөрәҗәгатьләрен имзалый;

8) Яшьләр координация Советының Эшче төркемнәре эшчәнлеген җитәкли;

9) Яшьләр координация Советы эшчәнлеге турында мәгълүматны Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарына һәм Яшьләр координация Советының барлык әгъзаларына җиткерүне тәэмин итә;

10) еллык һәм башка чорлардагы эшчәнлеге һәм Совет эшчәнлеге йомгаклары турында Яшьләр координация Советы утырышында хисап тапшыра;

11) үз компетенциясе кысаларында Яшьләр координация Советы эшчәнлегенә кертелгән башка мәсьәләләрне хәл итә.

6.4. Яшьләр координация Советы Рәисе вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) Яшьләр координация Советы Рәисе вәкаләтләрен туктату турында язмача гариза килү;

2) Яшьләр координация Советы Рәисенең эшчәнлеген туктату.

Яшьләр координация Советы Рәисен вазыйфасыннан читләштерү турында карар кабул итү белән бер үк вакытта Яшьләр координация Советы Рәисен яңадан сайлау турында карар кабул ителә һәм чираттагы утырыш датасы билгеләнә.

**7. Яшьләр координация Советы әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары**

7.1. Яшьләр координация Советы әгъзасы хокуклы:

- Советның җитәкче органнарына сайлау һәм сайлану;
- яшьләр сәясәте субъектлары белән хезмәттәшлек рәвешләрен билгеләргә;
- Яшьләр координация Советы утырышында карала торган мәсьәләләр буенча тавыш бирергә;
- утырышның көн тәртибе һәм аны уздыру тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә;
- Яшьләр координация Советы тарафыннан карала һәм кабул ителә торган карарлар проектларына тәкъдимнәр кертергә;
- Яшьләр координация Советы карарларының яңа проектларын эшләү кирәклеге турында мәсьәлә куярга;
- дәүләт яшьләр структураларыннан мәгълүмати, методик һәм башка ярдәмне алырга;
- Яшьләр координация Советында булган мәгълүматтан файдаланырга;
- муниципаль район яшьләр активының гомуми җыелышын чакыру инициативасы белән чыгарга.

7.2. Яшьләр координация Советы әгъзасы бурычлы:

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә, Яшьләр координация Советы турында нигезләмәне һәм Яшьләр координация советы утырышында рәислек итүченең хокукый таләпләрне үтәргә;
- Яшьләр координация Советы компетенциясе чикләрендә әлеге Нигезләмә нигезендә эш итәргә;

яшьләр инициативаларын һәм эшчәнлек юнәлешләрен гамәлгә ашыру программаларын эшләргә һәм гамәлгә кертергә;

- Яшьләр координация Советы утырышларында, шулай ук ул кергән Яшьләр координация Советының эшче төркемнәрендә шәхсән катнашырга. Җитди сәбәп аркасында килү мөмкин булмаганда, яшьләр Координация Советы Рәисен, яшьләр Координация СМоветының эшче төркеме җитәкчесен алдан кисәтергә;

- Яшьләр координация Советы Рәисенең үз компетенциясе чикләрендә йөкләмәләрен үтәргә;

- үз эшчәнлегеңдә һәм көндәлек тормышта җәмгыятьтә кабул ителгән әхлакый нормаларны һәм үз-үзеңне тотуның этик нормаларын үтәргә;

- Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтенең төп идеяләрен пропагандаларга.

**8. Йомгаклау нигезләмәләре**

8.1. Яшьләр координация Советы эшчәнлеген оештыру-методик һәм матди-техник тәэмин итүне еллык расланган чыгымнар сметасы кысаларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты һәм аның структур бүлекчәләре - Яшьләр сәясәте һәм спорт, мәгариф, мәдәният бүлекләре гамәлгә ашыра.

8.2. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән гамәлгә ашырыла.

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 1 февралендәге 49 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый координация Советы составы**

| | | |
|---|---|---|
| Платонова М.А. | - | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Яшьләр координация Советы Рәисе |
| Вәлиев А.А. | - | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге начальнигы, Яшьләр координация Советы Рәисе урынбасары |
| Савинов А.А. | - | «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе, Яшьләр координация Советы Рәисе урынбасары |
| Хәйруллина Г.Ф. | - | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге баш белгече, Яшьләр координация Советының җаваплы сәркатибы |
| | | Совет әгъзалары |
| Углева С.С. | - | Башкарма комитетның Опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы<br>Әлки муниципаль районы |
| Гайфуллина Р.А. | - | «Әлки районы мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы |
| Исхакова Г.Р. | - | «Әлки муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУнең әйдәп баручы белгече |
| Галимов Д.Р. | - | «Әлки район мәдәният йорты» МБУ директоры урынбасары |
| Емельшина Л.Г. | - | «Әлки район мәдәният йорты» МБУ сәнгать җитәкчесе |
| Захарова Н.П. | - | «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасары |
| Г. Я. Мардеева | - | «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУнең тәрбия эше буенча методисты |
| Заһидуллина Н.Х. | - | «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Психология-педагогика хезмәте педагог-психологы |
| Л.З. Абдрахманова | - | Әлки муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе; "Базарлы Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе" МАББУ директоры |
| Галиева Р.Ш. | - | «Базарлы Матак урта мәктәбе» МАББУ директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары |
| Яруллина Ф. Г. | - | «Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе» МБББУ директоры |
| Шагилиева А.Ф. | - | «Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе» МБББУ директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары |
| А.А.Гайфуллина | - | “Балалар иҗаты йорты” ӨБББ МБББУ директоры |
| Г. А. Ханафеева | - | “Балалар иҗаты йорты” ӨБББ МБББУ директоры |

| | | |
|---|---|---|
| | | урынбасары |
| Шәйхетдинов Р.С. | - | ӘМР "Юнармия" хәрби-патриотик хәрәкәтенең штабы начальнигы |
| Романов А.Н. | - | "Йолдыз" хәрби-патриотик клубы җитәкчесе |
| Платонов С.А. | - | "Оркестр" хәрби-патриотик клубы җитәкчесе |
| Протоирей Зиньков А.Н. | - | Әлки районы благочие; "Патриот" хәрби-спорт клубы җитәкчесе |
| Салахиев Ирек хәзрәт | - | Әлки районы имам-мөхтәсибе |
| Сәгыйров И.С. | - | «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча Яшьләр (мәктәп) формированиеләре СҮ» МБУ  начальнигы |
| Вафин Р.Р. | - | “Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” БӨББ МБББУ директоры |
| Хәлиуллина Г.Г. | | "Бердәм Россия" партиясенең җирле бүлеге җитәкчесе |
| Денисов Д.А. | - | "Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе" җирле бүлеге җитәкчесе |
| Гуляев Д.А. | - | Әлки муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе |
| Сәгыйтова Г.Ю. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе өлкән инспекторы |
| Зиннәтуллина Ф.Ф. | - | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибы |
| А.Р. Низамиев | - | «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесе - «Әлки хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире |